**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"29" ноябрь 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылы территориясендә 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Көек авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агачлар һәм куакларны кисү, (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); (Түбән Көек авылы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү));

2. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Түбән Көек авылы зиратын төзекләндерү: зиратка койма кору өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, (Түбән Көек авылының урам юлларын грейдлау кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү))

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Түбән Көек авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.